**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯҢА ЧИШМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2023 елның 19 нчы декабреннән — № 32-124

2019 елның 15 ноябрендәге 50-166 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең 15.11.2019 № 50-166 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә ( Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 31.05.2021 №10-32; 05.10.2021 №13-49; 14.12.2021 №16-58; 29.06.2022 №20-73; 10.03.2023 №26-97; 17.08.2023 29-111 карарлары редакциясендә) (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 22 статьясын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр Нигезләмәнең 25 статьясындагы 3 пунктының гамәлдә булуын туктатып торырга (Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр өлешендә бюджет турындагы карарлар нигезендә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм интернет-телекоммуникация челтәрендәге Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы — В. М. Козлов